ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 29 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 1 – 2, № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 3, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның 1 пунктында «студентлар спорт лигалары,» сүзләреннән соң «мәктәп спорт лигалары,» сүзләрен өстәргә;

2) 6 статьяда:
а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пункт өстәргә:
«$2^1$) республика спорт федерацияләрен дәүләт тарафыннан аккредитацияләү;»;
б) 2 өлешнең $4^1$ пунктында «студентлар арасында (шул исәптән студентларның спорт лигалары арасында)» сүзләрен «белем алучылар арасында (шул исәптән мәктәп спорт лигалары һәм студентлар спорт лигалары кысаларында)» сүзләренә алмаштырырга;

3) 11 статьяга түбәндәге эчтәлекле $4^1$ һәм $4^2$ өлешләр өстәргә:
«$4^1$. Спорт клублары түбәндәгеләргә хокуклы:
1) тренировка чараларын оештырырга, гражданнарның физкультура эшчәнлеген һәм физик тәрбиясен гамәлгә ашырырга;
2) рәсми физкультура чараларын һәм (яисә) спорт чараларын оештырырга һәм үткәрергә, шулай ук мондый чараларда гражданнарның катнашуын тәэмин итәргә;

3) Федераль закон нигезендә халыкны ГТО комплексы сынаулары (тестлары) нормативларын үтәүгә әзерләүне гамәлгә ашырырга.

$4^2$. Спорт клублары түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

1) гражданнарга физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудырырга;

2) физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче гражданнар арасында допингка каршы пропагандалауга, спорт өлкәсендә этик нормаларны үтәүгә юнәлдерелгән чаралар үткәрергә;

3) рәсми статистика исәбен алып баручы субъектларга Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсми статистик мәгълүмат булдыру өчен кирәкле беренчел статистик белешмәләрне һәм административ белешмәләрне түләүсез бирергә;

4) Россия Федерациясе законнары нигезендә башка бурычларны үтәргә.»;

4) 20 статьяның 1 өлешендәге 1 пунктында «хезмәткәрләргә физик культура һәм спорт» сүзләреннән соң «, шул исәптән корпоратив спорт,» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2020 ел, 19 ноябрь
№ 73-ТРЗ